КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 июнь г.Казань № 454

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 21 май, 413 нче, 2020 ел, 1 сентябрь, 772 нче; 2020 ел, 23 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 821 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1021 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 15 июнь, 566 нчы, 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче, 2023 ел, 11 март, 232 нче, 2023 ел, 19 август, 989 нчы, 2023 ел, 16 октябрь, 1312 нче, 2023 ел, 31 октябрь, 1377 нче, 2023 ел, 07 ноябрь, 1431 нче, 2024 ел, 11 май, 318 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян

итәргә;https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=RLAW363&n=178866&dst=102594

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының эшчеләр гомумтармак эшче һөнәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин